Республика Татарстан
СОВЕТ МУРТЫШ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д. 47, с. Муртыш-Тамак
423358
Телефон: 4-52-05

Татарстан Республикасы
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МОРТЫШТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет урамы, 47 йорт, Мортыштамак авылы,
423358
Телефон: 4- 52-05

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2015 елның 24 августы** **№ 8**

## Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге территориясендә адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләрен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 463-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Җирлекләр, шәһәр округлары, шәһәр эчендәге районнар территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләрен әзерләү өчен методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2017 елның 13 апрелендәге 711/пр номерлы боерыклары, Сарман муниципаль районының «Мортыштамак авыл җирлеге» уставы нигезендә Сарман муниципаль районы Советы карар итте.

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Мортыштамак авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү нормаларын һәм кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 20 июнендәге 9 номерлы Мортыштамак авыл җирлеге Советы карарына, кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Мортыштамак авылы, Сөлек авылы, Кормаш авылы торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Мортыштамак авыл җирлеге
башлыгы М.Н.Әхмәтгәрәев